Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

«16» июнь, 2023 ел № 110

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставы, 2023 елның 14 июнендәге 557 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2021 елның 08 декабрендәге 86 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Питрәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын (2022 елның 30 мартындагы 147 номерлы, 08.12.2022 елның 1 декабрендәге 202 номерлы үзгәрешләре белән) әзерләргә.

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.И. Шәйхисламов